## 9 – Т − 2016

**1. Борыны [борно]. Бу нинди фонетик күренеш?**
а) ассимиляция б) элизия
ә) диссимиляция в) редукция

**2. Ирен-ирен, ярым йомык, сонор тартык аваз:**
а) [б] б) [w]
ә) [п] в) [м]

**3. Кайсы төркем сүзләр тарихи сүзләргә керә?**
а) ярлык, тархан, имана б) түбәләү, олагу, чор
ә) җөмһүрият, сәясәт, шәкерт в) эпоха, гасыр, чор

**4. *Авылдашларга* сүзенең мәгънәле кисәкләргә бүленешен күрсәтегез:**
а) авыл-да-ш-лар-га б) авыл-даш-ла-рга
ә) авыл-даш-лар-га в) авыл-да-ш-ла-рга

**5. Бер составлы исем җөмләләрнең баш кисәге нәрсә белән белдерелә?**
а) фигыль белән белдерелә
ә) фигыльдән башка сүз төркемнәре белән белдерелә
б) теләсә нинди сүз төркеме белән белдерелә
в) исемнәр белән генә белдерелә

**6. К. Галинең "Кыйссаи Йосыф" әсәрендә Йосыф образына җыйнама характеристика бирелә. Аның ун сыйфаты барлыгы әйтелә.**

Беренчедән – буе зифа, сылу үзе,
Икенчедән – күрекле һәм якты йөзе,
Өченчедән – теле бик саф, туры сүзле,
Җитмеш ике телне тәмам белә имди!
Дүртенчедән – кешелекле һәм шәфкатьле,
Бишенчедән – Алып батырдай йөрәкле,
Алтынчыдан – бик күпләрдән ул куәтле, −
Көч-куәте кырык ирдән артык имди.
Җиденчедән – дине бөтен, диянәтле,
Сигезенче – хыянәтсез, әманәтле,
Тугызынчы – холкы гүзәл, теле татлы,
Унынчыдан – ...

Йосыфка хас унынчы сыйфатны дөрес билгеләгез.
а) Сәүдәгәрләр нәсле имди б) Фиргәвеннәр нәсле имди
ә) Пәйгамбәрләр нәсле имди в) Зәркәнчеләр нәсле имди

**7. "Кодекс куманикус" хезмәте − ...**
а) Ярлык б) Сәяхәтнамә
ә) Сүзлек в) Дастан?

**8. "Оҗмахларның ачык юлы" әсәренең авторы кем?**
а) М. Болгари б) Х. Кятиб
ә) С. Сараи в) К. Саяди

**9. Сәйф Сараи тудырган образларны атагыз.**
а) Йосыф һәм Зөләйха б) Ләйлә һәм Мәҗнүн
ә) Сөһәйл һәм Гөлдерсен в) Таһир һәм Зөһрә.

**10. Башка бер авторның теге яки бу әсәре тәэсирендә туган, аңа охшатып язылган әсәр ничек атала?**
а) Копия б) Касыйдә
ә) Назыйрә әсәр в) Тәрҗемә.

## 10 – Т − 2016

**1. Татар халкында XVI–XIX йөзләрдә кулланылган әдәби телне билгеләгез:**

а) борынгы төрки теле б) иске татар әдәби теле
ә) иске төрки әдәби теле в) хәзерге татар әдәби теле

**2. Татар язуы (алфавиты) ничәнче елда рус алфавитына күчә?**

а) 1917 елда
ә) 1927 елда
б) 1939 елда
в) 1945 елда

**3. Үзенчәлекле тартык аваз [’](һәмзә) язуда нинди хәрефләр белән белдерелә?**

а) я, ь,ъ
ә) э,ъ
б) э, ь, ъ
в) язуда белдерелми

**4. Сингармонизм законына буйсынган сүзләрне билгеләгез:**

а) Мәрьям, үзсүзле, ата-ана, бодай
ә) Миңсылу, бераздан, дөньяви, гөлҗимеш
б) эни, гөлләмә, ир-ат, һәрвакыт
в) гадәт, дилбегә, ылыслы, зәңгәрсу

**5.** ***Быел яңгыр аз яуды: игендә өмет зур түгел. (Г.Ибраһимов)*** **Иярчен җөмләнең төрен билгеләгез.**

а) иярчен максат җөмлә
ә) иярчен вакыт җөмлә
б) иярчен сәбәп җөмлә
в) иярчен ия җөмлә

**6. 1906 елның 21нче апрелендә Уфа яшьләре Г. Исхакыйның сәхнә әсәрен клубта куярга рөхсәт алалар. Моны киң җәмәгатьчелек алдында куелган беренче татарча спектакль дип санарга мөмкин. Сүз татар классигының нинди әсәре турында бара?**

а) “Алдым-бирдем” б) “Ике гашыйк”
ә) “Өч хатын белән тормыш” в) “Бай углы”

**7. Хәят дачага әзерләнә башлый: декольте күлмәген кия, куе кара чәчләренә кечкенә калфак кадап куя. “*Бу калфак, − ди язучы, − ефәк көлтәсенә чолганган (........................) шикелле, көлеп тора иде*”. Җәя эченә дөрес вариантны урнаштырыгыз.**

а) Кычыткан (крапива) б) Кәнәфер (гвоздика)
ә) Гөл чәчәге (роза) в) Кыңгырау чәчәге (колокольчик)

**8.Апуш кайсы шагыйрьнең псевдонимы?**

а) С. Рәмиев б) Н. Думави
ә) Г.Тукай в) М. Гафури

**9.** ***“Илдә бер дуст булмаса гәр, ил бөтен дошман түгел”.*** **Бу кинаяле юлларның авторы кем?**

а) Г. Тукай б) С. Рәмиев
ә) Дәрдмәнд в) Х. Туфан

**10. Ш. Камалның “Акчарлаклар” әсәрендә акчарлаклар образларның кайсы төренә карый?**

а) Символик образ б) Образ-предмет
ә) Аллегорик образ г) Образ-кичереш

## 11 – Т − 2016

**1. Татар һәм башкорт телләре кайсы телләр гаиләсенә карый?**

а) һинд-европа  б) фин-угор

ә) семит-хәмит  в) төрки

**2. Татар халкын формалаштыруда катнашкан борынгы төрки кабиләләрне билгеләгез.**

а) бәҗәнәкләр (печенеги), балкарлар, угызлар

ә) аланнар, хакаслар, казахлар

б) пермяклар, зыряннар, марилар

в) болгарлар, бортаслар, суварлар

**3. Хәзерге татар телендә сузык авазлар ничә хәреф белән белдерелә?**

а) 8

ә) 9

б) 11

в) 12

**4. *Кәгазь, шагыйрь, канәгать, гамьсез, гарьлек* кебек сүзләрдә ни өчен *ь* хәрефе языла?**

а) сүзләрне аеру өчен

ә) иҗекнең нечкәлеген белдерү өчен

б) алдагы тартыкның нечкәлеген белдерү өчен

в) сүзләрне нечкәртеп уку өчен

**5. *Бияләе* сүзендә ничә аваз бар?**

а) 6 аваз

ә) 7 аваз

б) 8 аваз

в) 9 аваз

6. **“Инде көз булды, Гөлсем туташ, көз; һәр агачның җимеше പеште,...” Җөмләне дөрес итеп дәвам итегез.**

а) Миләшнеке – миләшчә, алманыкы – алмача

ә) Миләшнеке – миләшчә, баланныкы – баланча

б) Баланныкы – баланчы, алманыкы – алмача

в) Алманыкы – алмача, чиянеке – чиячә.

**7. Н. Исәнбәткә нинди хезмәте өчен Г. Тукай исемендәге Дәүләт бүләгенә лаек була?**

а) “Идегәй” трагедиясе өчен  б) “Син сазыңны уйнадың” шигыре өчен

ә) “Татар халык мәкальләре” өчен  в) “Түләк һәм Сусылу” либреттосы өчен

**8. “Җырлап үттем данлы көрәш кырын,**
**Җырлап килдем тормыш язымa.**
**Соңгы җырым палач балтасына**
**Башны тоткан килеш язылa” – бу кемнең юллары?**

а) Фатих Кәрим  б) Муса Җәлил

ә) Абдулла Алиш  в) Мостай Кәрим

**9. Ф. Кәримнең “Гөлсем”, “Идел егете”, “Кыңгыраулы яшел гармун”, “Пионерка Гөлчәчәккә хат”, “Тирән күл”, “Үлем уены”, “Партизан хатыны”, “Өмет йолдызы” әсәрләре нинди жанрда иҗат ителгәннәр?**

а) Поэма  б) Мәсәл

ә) Баллада  в) Либретто

**10. “Акылы кушканча түгел, күңеле кушканча йөри торган бәндәләр дә була бит”. Г. Бәширов “Намус ” әсәрендә кемгә шундый характеристика бирә?**

а) Нәфисәгә  б) Мәүлиха түтигә

ә) Мишәр хатыны Әпипәгә  в) Зәйнәпбануга